КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 24 май г.Казань № 484

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган, ата-ананың берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яки) балаларының берсе генә булса да инвалид бала булган гаилә әгъзаларына ай саен пособие бирү турында» 2019 ел, 7 сентябрь, 803 нче карары белән расланган 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган, ата-ананың берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яки) балаларының берсе генә булса да инвалид бала булган гаилә әгъзаларына ай саен пособие бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган, ата-ананың берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яки) балаларының берсе генә булса да инвалид бала булган гаилә әгъзаларына ай саен пособие бирү турында» 2019 ел, 7 сентябрь, 803 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 26 декабрь, 120 нче; 2020 ел, 17 апрель, 304 нче; 2020 ел, 11 сентябрь, 827 нче; 2021 ел, 10 апрель, 236 нчы; 2022 ел, 28 гыйнвар, 66 нчы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган, ата-ананың берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яки) балаларының берсе генә булса да инвалид бала булган гаилә әгъзаларына ай саен пособие бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта:

дүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

җиденче абзацта «тикшерү органнары яки суд карары нигезендә суд-медицина экспертизасын узуга бәйле рәвештә» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Ай саен пособие бирү максатларында гаиләнең уртача җан башына кереме, «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән балага ай саен бирелә торган пособиене исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2016 ел, 10 сентябрь, 625 нче карары белән расланган Балага ай саен бирелә торган пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү тәртибенең 1.3, 2.1 («к» пунктчаның унсигезенче абзацыннан тыш), 2.2 – 3.1, 4.2, 5.1 – 5.15 пунктларында билгеләнгән кагыйдәләр буенча исәпләп чыгарыла.

түбәндәге эчтәлекле $4^1$ һәм $4^2$ пунктлар өстәргә:

«$4^1$. Ай саен бирелә торган пособие алу хокукы билгеләнгәндә (шул исәптән гаиләнең уртача җан башына керемен исәпләп чыгару максатларында) исәпкә алына торган гаилә составына ата-ана (шул исәптән уллыкка алучы), аның ире (хатыны), балигъ булмаган балалары (аларның уртак балалары булмаган, ата-ананың, аның иренең (хатынының) алимент йөкләмәләре барлыкка килгән балигъ булмаган балаларыннан тыш) кертелә.

$4^2$. Ай саен бирелә торган пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача кереме ай саен бирелә торган пособие билгеләү турында гариза (алга таба – гариза) бирелгән ай алдындагы соңгы алты календарь айга гаилә әгъзалары керемнәре суммасыннан чыгып исәпләнә.»;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Ай саен бирелә торган пособие билгеләү өчен алучы, алучының законлы вәкиле яки Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә аның тарафыннан вәкаләт бирелгән зат (алга таба – гариза бирүчеләр), үзләренең тормыш хәле нинди булуга карамастан, яшәү урыны буенча «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе бүлегенә (алга таба – Үзәк бүлеге) түбәндәгеләрне тапшыра:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча банкта яки башка кредит оешмасында ачылган шәхси счет реквизитларын күрсәтеп, гариза,

гариза бирелә торган айга кадәрге соңгы алты календарь айга алучының һәм аның гаилә әгъзаларының керемнәрен раслый торган документларны;

чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән бала туу турында таныклык күчермәсен һәм аның нотариаль таныкланган рус теленә тәрҗемәсе күчермәсен;

чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән никахлашуны теркәү турында таныклык күчермәсен һәм аның нотариаль таныкланган рус теленә тәрҗемәсе күчермәсен;

ышанычлы затлар өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә күчермәсен;

гариза бирүченең яки аның гаилә әгъзаларының суд карары буенча мәҗбүри дәваланууда булуы турында мәгълүмат бирелгән документны;

гариза бирүчегә һәм (яки) аның гаилә әгъзаларына карата сак астына алу рәвешендә чикләү чараларын куллану турында мәгълүмат бирелгән документны;

алучының гаилә әгъзаларыннан яки аларның законлы вәкилләреннән түбәндәгеләрне раслый торган документны (документларны) (ирекле формада):

аларның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы булуын;

шәхси мәгълүматны органга яки оешмага тапшырганда гариза бирүченең алар исеменнән эш итүгә вәкаләтен.

Документларның күчермәләре нотариус яки документның төп нөсхәсе бирелгән орган (учреждение) тарафыннан таныкланмаган очракта, алар төп нөсхәләре белән тапшырыла һәм Үзәк бүлеге белгече тарафыннан таныклана.

Гариза почта аша җибәрелгәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланган булырга тиеш.»;

7 пунктта «ай саен бирелә торган пособие билгеләү турында гариза алынган» сүзләрен «билгеләнгән тәртиптә гариза теркәлгән» сүзләренә алмаштырырга;

12 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гаиләдә инвалид ата-аналарның яки инвалид балалар булган балаларның булмавы.»;

19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Дөрес булмаган мәгълүмат бирү, ай саен бирелә торган түләүләр алу хокукына йогынты ясый торган мәгълүматны яшерү, Үзәк бүлеге тарафыннан аны исәпләгәндә җибәрелгән исәп-хисап хаталары аркасында ай саен бирелә торган пособиенең артык түләнгән суммасы алучы тарафыннан ирекле рәвештә «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенең казначылык счетына күчерү юлы белән яки ай саен бирелә торган пособиенең алга таба алыначак суммасы исәбеннән кире кайтарыла, ә алучы баш тарткан очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә түләтелә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин